Республика Татарстан
СОВЕТ
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел 7 нче ноябрь № 4

**Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә 2024 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Фермы Сәүкле торак пунктында халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгы

КАРАР чыгарды:

1. 2023 елның 17 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы, Фермы Сәүкле авылы, Тукай урамы, 2 нче йорт янында урамда 2024 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең Фермы Сәүкле авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Фермы Сәүкле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, сроклы хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт үтәүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1) Фермы Сәүкле торак пунктында зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

"ӘЙЕ " " КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Антонов Ю.Г.